**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

«04» март 2026 ел № 2 Урыссу ш.т.б.

Ютазы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның 2025 елгы планы (программасы) үтәлеше турында хисапны раслау хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 21.12.2001 ел, № 178-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 30.05.2008 ел, № 115 карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында"гы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы "Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның 2025 елгы планы (программасы) үтәлеше турында кушымтада бирелә торган хисапны расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Законлылык, регламент һәм җирлекләр советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин